АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 10.12.2025 1918 **КАРАР**

Алабуга муниципаль районы Алабуга шәһәре халкын ышыклап тору өчен җайлаштырылган җир асты киңлегендәге тирәнәйтелгән урыннар булдыру һәм файдалануга даими әзерлек халәтендә тоту турында

«Гражданнар оборонасы турында» 1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Гражданнар оборонасының ышыклап тору урыннары һәм башка объектларын төзү тәртибе турында» 1309 номерлы карары, Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының «Муниципаль берәмлекләрдә һәм оешмаларда гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы Нигезләмәне раслау турында» 2008 елның 14 ноябрендәге 687 номерлы боерыгы нигезендә, Алабуга муниципаль районы Алабуга шәһәре халкын оборонасын һәрьяклап тәэмин итүне оештыру максатларында, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Алабуга муниципаль районы Алабуга шәһәре халкын ышыклап тору өчен җайлаштырылган җир асты киңлегендәге тирәнәйтелгән урыннар булдыру һәм файдалануга даими әзерлек халәтендә тоту турындагы Нигезләмәне расларга (1 нче кушымта).
2. Алабуга муниципаль районы Алабуга шәһәре халкын ышыклап тору өчен күпфатирлы торак йортларның җайлаштырылган тирәнәйтелгән ышыклану урыннары (подваллары) реестрын расларга (2 нче кушымта).
3. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына, халыкны ышыклап тору өчен җайлаштырылган җир асты киңлегендәге тирәнәйтелгән урыннарның гамәлдә булуын исәпкә алуны оештырырга.

3.1 Халыкны ышыклап тору өчен елына кимендә 1 мәртәбә билгеләнгән тирәнәйтелгән урыннарны карап тотуны тикшерү графигын булдырырга;

3.2 Ел саен агымдагы елның 1 гыйнварына кадәр булган вакыт эчендә халыкны ышыклап тору өчен билгеләнгән тирәнәйтелгән урыннар исемлегенә төзәтмәләр кертергә.

4. «Халыкны ышыклап тору өчен тирәнәйтелгән урыннарны җайлаштыру» «Россиянең дәүләт стандарты» 42.4.16 - 2023 таләпләре нигезендә торак-коммуналь хуҗалыгы идарәче оешмасы һәм торак милекче ширкәте җитәкчеләренә тирәнәйтелгән урыннарны (подвалларны) әзерләү эшен оештыруны тәкъдим итәргә:

4.1. Күпфатирлы торак йортларның подъездларына «Барыгызга да игътибар!» кисәтү сигналын алганда алардан файдалану тәртибе турында белешмә урнаштыру юлы белән халыкка хәбәр итәргә.

4.2. Гражданнар оборонасының «Барыгызга да игътибар!» кисәтү сигналын алганда җир асты урыннарына тоткарлыксыз керү мөмкинлеген тәэмин итәргә.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Алабуга муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкчесе вазифаларын башкаручы А.А.Томилин

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН
ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 5D5B832C0D4CC8A96C405A04F5061337
Владелец: Томилин Андрей Александрович
Действителен с 25.09.2024 до 19.12.2025

Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
2025 елның ____ ____ ___
номерлы карарына
1 нче кушымта

**Алабуга муниципаль районы Алабуга халкын ышыклап тору өчен җайлаштырылган җир асты киңлегендәге тирәнәйтелгән урыннар булдыру һәм файдалануга даими әзерлек халәтендә тоту турында Нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Алабуга муниципаль районының Алабуга шәһәре территориясендә халкын ышыклап тору өчен җайлаштырылган җир асты киңлегендәге тирәнәйтелгән урыннар булдыру һәм даими әзерлек хәлендә тоту турындагы Нигезләмә (алга таба - Алабуга шәһәре) «Гражданнар оборонасы турында» 1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Гражданнар оборонасының ышыклап тору урыннары һәм башка объектларын төзү тәртибе турында» 1309 номерлы карары нигезендә эшләнде һәм Алабуга шәһәре территориясендә халыкны ышыклап тору өчен җайлаштырылган җир асты киңлегендәге тирәнәйтелгән урыннарны булдыру һәм файдалануга даими әзерлек халәтендә тоту тәртибен билгели.

1.2. Нигезләмәдә кулланыла торган төп төшенчәләр:

1.2.1. Халыкны ышыклап тору өчен җайлаштырылган җир асты киңлегендәге тирәнәйтелгән урыннар яисә корылмалар тулысынча яисә өлешчә грунтка тирәнәйтелгән, киртәләү һәм таяныч төзелеш конструкцияләре белән чикләнгән өлеше, ул ышыкланучы халыкны гадәти зарарлау чараларының фугаслы кыйпылчык тәэсиреннән саклау;

1.2.2. Җайлаштырылган җир асты киңлегендәге тирәнәйтелгән урыннар һәм башка корылмалар тыныч вакытта гражданнар оборонасы буенча чаралар үткәрүне тәэмин итү;

1.2.3. Җайлаштырылган җир асты киңлегендәге тирәнәйтелгән урыннарны һәм башка корылмаларны мобилизация һәм сугыш чорында халыкны ышыклап тору өчен файдалану һәм җайлаштыру.

1.2.4. Тыныч вакытта җайлаштырылган җир асты киңлегендәге тирәнәйтелгән урыннар һәм башка корылмалар Алабуга шәһәре халкына хезмәт күрсәтүдә һәм аны табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр китереп чыгарган зарарлы факторлардан саклауда, ышыклангыын халыкны гадәти зарарлау чараларының фугаслы һәм кыйпылчыклы тәэсиреннән саклаудан файдалану.

1.2.5. Әлеге Нигезләмәнең гамәлдә булуы Алабуга муниципаль районының Алабуга шәһәре территориясендә урнашкан, оештыру-хокукый рәвешләренә һәм милек рәвешләренә бәйсез рәвештә, җайлаштырылган җир асты киңлегендәге тирәнәйтелгән урыннарга, объектларга ия һәм алардан файдаланучы оешмаларга, предприятиеләргә, учреждениеләргә кагыла.

## II. Җайлаштырылган җир асты киңлегендәге тирәнәйтелгән урыннарның яраклылыгын исәпкә алу һәм билгеләү тәртибе

2.1 Җайлаштырылган җир асты киңлегендәге тирәнәйтелгән урыннарны күпчелек ышыкланучы халыкл яши торган урыннарга якын урнаштыру;

Җайлаштырылган җир асты киңлегендәге тирәнәйтелгән урыннарны сайлаганда халык ышыкланып торган урыннарда, янгын куркынычы янамаган өстенлек бирү, ава торган конструкцияләрне һәм агачларны булдырмау;

2.2. Халыкны яшерү өчен файдаланыла торган тирәнәйтелгән урыннарга инвентаризация «Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы Төзелеш департаменты» МКУ тарафыннан гамәлгә ашыру;

2.3. Җайлаштырылган җир асты киңлегендәге тирәнәйтелгән урыннарның файдалану өчен яраклылыгын билгеләү Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты төзелгән комиссия тарафыннан гамәлгә ашырыла, урыннарны һәм корылмаларны тикшерү һәм проектлау хокукына керү хокукы булган оешмалар, шулай ук гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр өлкәсендәге белгечләрне, әлеге урыннарның милекче вәкилләрен җәлеп итү.

2.4. Тирәнәйтелгән урыннарның халыкны ышыклау өчен яраклылык критерийлары булып түбәндәгеләр тора:

- тирәнәйтелгән урыннарга керү юлының саны кимендә икене булдыру;
- тирәнәйтелгән урыннар һәм корылмалар җир өстендә югары катларда урнашкан биналар җимерелгәндә, яңгыр, җир асты сулары, шулай ук башка сыеклыклар белән су басудан саклау;
- биналарның биеклеге 1,5 м дан да ким итмәү;
- төп бүлмәләрнең идән мәйданы нормасы бер кешегә 0,6 кв. м итеп санала;
- табигый вентиляцияне күздә тоту;
- санузеллар булмаганда герметик савытлар өчен аерым бүлмәләр карау;
- электр яктырту, ул булмаган очракта, кул астындагы чаралар (шәмнәр, аккумуляторлар, фонарь һ. б.) булдыру;
- эчә торган су запасы савытларын урнаштыру урыннарын истә тоту.

## III. Җайлаштырылган җир асты киңлегендәге тирәнәйтелгән урыннарны булдыру һәм әзерлек халәтендә тоту тәртибе

3.1. Җайлаштырылган җир асты киңлегендәге тирәнәйтелгән урыннар халыкны ышыклап тоту өчен гадәттән тыш хәлләр килеп чыккан очракта

кешеләрнең әлеге урыннарда имин булуларын тәэмин итүгә юнәлдерелгән оештыру һәм инженер-техник чаралар комплексын үз эченә алу.

3.2. Җайлаштырылган җир асты киңлегендәге тирәнәйтелгән урыннар халыкны ышыклап тоту өчен җайлаштыру чаралары үз эченә түбәндәгеләрне ала:

- урыннардан чит әйберләрне һәм чүп-чарны чистарту;
- урыннарны герметизацияләү (ярыкларны, чатнауларны, коммуникацияләр үткән урыннардагы тишекләрне томалау);
- ишекләр, люклар урнаштыру яки җайлаштыру, яшеренүчеләрне кабул итү урыннарын җиһазлау;
- вентиляция җайланмаларын җиһазлау;
- эскәмияләр, утыру һәм яту урыннары урнаштыру;
- авария хәлендәге яктырту җайланмасын алыштыру;
- эчәргә яраклы су запасы булдыру;
- урынны гади санитар приборлар белән тәэмин итү;
- җимерелгән чыгу юлларын ачу өчен инструментлар резервын булдыру.

3.3. Җайлаштырылган җир асты киңлегендәге тирәнәйтелгән урыннарны җайлаштыру һәм әзерлектә тоту өчен аларның милекчеләре яки әлеге урыннарны эксплуатацияләүче оешмалар җаваплы.

3.4. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр бүлеге җайлаштырылган җир асты киңлегендәге тирәнәйтелгән урыннар халыкны ышыклап тору өчен җайлаштыру эшләренә методик җитәкчелек итә һәм координацияләүне гамәлгә ашыра.

3.5. Җайлаштырылган җир асты киңлегендәге тирәнәйтелгән урыннарны файдалануга әзерлек халәтендә тоту өчен түбәндәгеләр каралган:

- урыннарның торышын даими планлы тикшереп тору;
- инженер-техник җиһазларга техник хезмәт күрсәтү һәм агымдагы ремонт ясау;
- урыннардан билгеләнеше буенча файдалануны тикшереп тору;
- профилактик һәм дезинфекция чаралары.

## IV. Җайлаштырылган җир асты киңлегендәге тирәнәйтелгән урыннар һәм башка корылмалары фондын булдыру

4.1. Җайлаштырылган җир асты киңлегендәге тирәнәйтелгән урыннарын һәм башка корылмаларын булдыру Алабуга шәһәре территориясендә гражданнар оборонасын алып бару тәртибен һәм оештыруны регламентлаучы законнар, норматив актлар, норматив-техник һәм башка документлар нигезендә алдан карала һәм тыныч вакытта гамәлгә ашырыла.

4.2. Җайлаштырылган җир асты киңлегендәге тирәнәйтелгән урыннарга һәм башка корылмаларга ихтыяҗ халык саныннан чыгып, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан билгеләнә.

4.3. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җайлаштырылган җир асты киңлегендәге тирәнәйтелгән урыннарны һәм башка корылмаларны эксплуатацияләүне һәм халыкны кабул итүгә әзерлек халәтендә тотуны контрольдә тота.

4.4. Алабуга шәһәре территориясендә эшчәнлек алып баручы идарәче компанияләр һәм торак милекче ширкәтләре торак биналарның җайлаштырылган җир асты киңлегендәге тирәнәйтелгән урыннарында һәм башка корылмаларында халыкны ышыклап тору өчен файдалануны тәэмин итәләр.

## V. Җайлаштырылган җир асты киңлегендәге тирәнәйтелгән урыннарын һәм башка корылмаларын саклау

5.1. Алабуга шәһәре территориясендә урнашкан һәм көндәлек эшчәнлек режимында файдаланыла торган җайлаштырылган җир асты киңлегендәге тирәнәйтелгән урыннарны һәм башка корылмаларны тыныч һәм сугыш чорында гадәттән тыш халәтендә саклау.

5.2. Көндәлек эшчәнлек, гадәттән тыш хәл режимнарында һәм сугыш чорында җайлаштырылган җир асты киңлегендәге тирәнәйтелгән урыннанын һәм башка корылмаларны саклау, эксплуатацияләү һәм аларны әзерлек хәлендә тоту «Халыкны ышыклап тоту өчен каралган урыннарны урнаштыру» «Россиянең дәүләт стандарты» 42.4.16-2023 таләпләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

5.3. Җайлаштырылган җир асты киңлегендәге тирәнәйтелгән урыннарны һәм башка корылмаларны көндәлек эшчәнлек режимында эксплуатацияләгәндә, тыныч һәм сугыш чорында, гадәттән тыш хәлләрдә дә җайлаштырылган җир асты киңлегендәге тирәнәйтелгән урыннарда һәм башка корылмаларында кешеләрне кабул итүгә даими әзерлек тәэмин итү таләпләрен үтәү.

Шул ук вакытта җайлаштырылган җир асты киңлегендәге тирәнәйтелгән урыннарның һәм башка корылмаларның тулаем һәм аерым элементларының сакланышын тәэмин итү.

5.4. Җайлаштырылган җир асты киңлегендәге тирәнәйтелгән урыннарны һәм һәм башка корылмаларны карап тоту һәм эксплуатацияләү РФ Хөкүмәтенең «Хосусыйлаштырылган предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар тарафыннан гражданнар оборонасы объектларыннан файдалану тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында» 1994 елның 23 апрелендәге 359 номерлы карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Җайлаштырылган җир асты киңлегендәге тирәнәйтелгән урыннарның һәм башка корылмаларның янгынга каршы таләпләрне үтәү өлешендә Россия Федерациясендә янгын куркынычсызлыгы таләпләренә таянып эш итела.

5.5. Торак-коммуналь хуҗалык оешмалары, торак милекче ширкәте җитәкчеләре җайлаштырылган җир асты киңлегендәге тирәнәйтелгән урыннарын һәм башка корылмаларын тиешенчә файдалануга әзерләү, эксплуатацияләү һәм карап тоту өчен гамәлдәге законнар нигезендә җаваплылык тоталар.

## VI. Җайлаштырылган җир асты киңлегендәге тирәнәйтелгән урыннар һәм башка корылмаларыннан билгеләнгән максат буенча файдалануга әзерлек хәлендә тоту һәм файдалану

6.1. Тыныч чорда җайлаштырылган җир асты киңлегендәге тирәнәйтелгән урыннар һәм башка корылмалар халыкка хезмәт күрсәтү мәнфәгатьләрендә, шулай ук халыкны табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр китереп чыгарган зарарлы факторлардан саклау, халыкны ышыклап тору максатларында кулланууга билгеләнгән, аның даими әзерлек халәтендә торуы гадәти зарарлану чараларының фугаслы һәм кыйпылчыклы тәэсиреннән саклау өчен файдаланыла.

6.2. Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда, шулай ук хәрби хәл киеренкелгәндә, җайлаштырылган җир асты киңлегендәге тирәнәйтелгән урыннар мөмкин кадәр кыска вакыт эчендә халыкны кабул итүгә әзер тора.

6.3. Халыкны ышыклап тору өчен җайлаштырылган җир асты киңлегендәге тирәнәйтелгән урыннар булдыру һәм файдалануга даими әзерлек халәтендә тоту турындагы карарны Алабуга муниципаль районының Гражданнар оборонасы җитәкчесе һәм Алабуга муниципаль районының Башкарма комитеты җитәкчесе кабул итә.

6.4. Халыкны ышыклап тору өчен җайлаштырылган җир асты киңлегендәге тирәнәйтелгән урыннар булдыру һәм файдалану чорында:түбәндәгеләр тыела:

- урыннарга тиз кабынып китә торган һәм шартлаучан матдәләр алып килү һәм саклау;
- тәмәке тарту һәм ачык уттан файдалану;
- вакытлыча электр челтәрләре урнаштыру һәм үзалмалы электр челтәренә тоташтыру;
- биналарның керү һәм чыгу юлларын томалау.

6.5. Җайлаштырылган җир асты киңлегендәге тирәнәйтелгән урыннар булдыру һәм файдалануга даими әзерлек халәтендә тоту Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының «Халыкны ышыклап тору өчен каралган урыннарны урнаштыру» «Халыкны ышыклап тору өчен тирәнәйтелгән урыннарны җайлаштыру» «Россиянең дәүләт стандарты» 42.4.16-2023 таләпләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

6.6. Мөлкәтне урнаштыру һәм берләштерү граждан оборонасы объектларын карау, аларга хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау өчен техник


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

урыннарга һәм инженер-техник җиһазларга даими ирекле керүне тәэмин итүне исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

## VII. Җайлаштырылган җир асты киңлегендәге тирәнәйтелгән урыннарны һәм башка корылмаларны булдыру һәм әзерлек халәтендә тоту чараларын финанслау

7.1. Алабуга муниципаль районы Алабуга шәһәре халкын ышыклап тору өчен җайлаштырылган җир асты киңлегендәге тирәнәйтелгән урыннар булдыру һәм файдалануга даими әзерлек халәтендә тоту чараларын тәэмин итү муниципаль берәмлек бюджетының чыгым йөкләмәсе булып тора.

7.2. Барлык оештыру-хокукый милек формасындагы оешмаларның җайлаштырылган җир асты киңлегендәге тирәнәйтелгән урыннарны һәм башка корылмаларны булдыру һәм әзерлек халәтендә тоту һәм саклап калу чараларын гамәлдәге законнар нигезендә тәэмин итү әлеге оешмаларның чыгым йөкләмәсе булып тора.

## VIII. Халыкка хәбәр итү (җиткерү)

8.1. Җайлаштырылган җир асты киңлегендәге тирәнәйтелгән урыннар һәм башка корылмалар урнашкан урыны турында халыкка мәгълүмат бирү массакүләм мәгълүмат чаралары, Алабуга муниципаль районының рәсми сайты, торак йортлардагы һәм җәмәгать биналарындагы мәгълүмат стендлары аша гамәлгә ашырыла.

8.2. Укыту-консультация пунктлары, Татарстан Республикасының Алабуга муниципаль районы буенча гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр бүлеге халык арасында җайлаштырылган җир асты киңлегендәге тирәнәйтелгән урыннардан һәм башка корылмаларнынннан файдалану тәртибе турында аңлату эшләре алып барыла.

8.3. Милекчеләр яисә эксплуатацияләүче оешмалар җайлаштырылган җир асты киңлегендәге тирәнәйтелгән урыннарның һәм башка корылмаларның күрсәткечләре һәм билгеләре булуын тәэмин итә.

Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
2025 елның ____ ____ ___
номерлы карарына
2 нче кушымта

2. Алабуга муниципаль районы Алабуга шәһәре халкын ышыклап тору өчен күпфатирлы торак йортларның җайлаштырылган тирәнәйтелгән ышыклану урыннары (подваллары) реестрын

| № т/н | Кертелгән төркемдәге исемлек нигезендә объектның тибы | Объект урнашкан урынның тулы адресы | Объектны файдаланучы оешманың исеме | Объектның кеше сыйдырышлылыгы (өйдә яшәүчеләр) | Яшерен үчеләрнең фактик кешеләр саны | Объектның гомуми мәйданы, кв. м. | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| 1 | Торак йорнынţ подвалы | Алабуга шәһәре, Интернациональная урамы, 6 нчы йорт | «Жилкомфортсервис» ИК ЖЧЖ; | 70 | 1328 | 797 | |
| 2 | Торак йорнынţ подвалы | Алабуга шәһәре, Карьерный тыкрыгы, 1 нче йорт | «Жилкомфортсервис» ИК ЖЧЖ; | 600 | 821 | 493 | |
| 3 | Торак йорнынţ подвалы | Алабуга шәһәре, Мир урамы, 1 нче йорт | «Жилкомфортсервис» ИК ЖЧЖ; | 580 | 1625 | 975 | |
| 4 | Торак йорнынţ подвалы | Алабуга шәһәре, Мир урамы, 13 нче йорт | «Жилкомфортсервис» ИК ЖЧЖ; | 1500 | 1633 | 980 | |
| 5 | Торак йорнынţ подвалы | Алабуга шәһәре, Мир урамы, 14 нче йорт | «Жилкомфортсервис» ИК ЖЧЖ; | 500 | 2113 | 1268 | |
| 6 | Торак йорнынţ подвалы | Алабуга шәһәре, Мир проспекты, 24 нче йорт | «Жилкомфортсервис» ИК ЖЧЖ; | 290 | 4226 | 2536 | |
| 7 | Торак йорнынţ подвалы | Алабуга шәһәре, Мир ур., 30 нчы йорт | «Жилкомфортсервис» ИК ЖЧЖ; | 3000 | 3550 | 2130 | |
| 8 | Торак йорнынţ подвалы | Алабуга шәһәре, Мир урамы, 33 нче йорт | «Жилкомфортсервис» ИК ЖЧЖ; | 1500 | 1840 | 1104 | |
| 9 | Торак йорнынţ подвалы | Алабуга шәһәре, Мир проспекты, 49 нчы йорт | «Жилкомфортсервис» ИК ЖЧЖ; | 490 | 2330 | 1338 | |
| 10 | Торак йорнынţ подвалы | Алабуга шәһәре, Мир проспекты, 71 нче йоррт | «Жилкомфортсервис» ИК ЖЧЖ; | 195 | 611 | 367 | |
| 11 | Торак йорнынţ подвалы | Алабуга шәһәре, Матросов урамы, 2 нче йорт | «Жилкомфортсервис» ИК ЖЧЖ; | 160 | 726 | 436 | |
| 12 | Торак йорнынţ подвалы | Алабуга шәһәре, Матросов урамы, 4 нче йорт | «Жилкомфортсервис» ИК ЖЧЖ; | 370 | 1100 | 660 | |
| 13 | Торак йорнынţ подвалы | Алабуга шәһәре, Молодёжная урамы, 20 нче йорт | «Жилкомфортсервис» ИК ЖЧЖ; | 670 | 2870 | 1722 | |
| 14 | Торак йорнынţ подвалы | Алабуга шәһәре, Пролетарская урамы, 2А нче йорт | «Жилкомфортсервис» ИК ЖЧЖ; | 585 | 1461 | 877 | |
| 15 | Торак йорнынţ подвалы | Алабуга шәһәре, Пролетарская урамы, 6 нчы йорт | «Жилкомфортсервис» ИК ЖЧЖ; | 335 | 1278 | 767 | |
| 16 | Торак йорнынţ подвалы | Алабуга шәһәре, Пролетарская урамы, 6А нчы йорт | «Жилкомфортсервис» ИК ЖЧЖ; | 335 | 1006 | 604 | |
| 17 | Торак йорнынţ подвалы | Алабуга шәһәре, Пролетарская урамы, 8 нче йорт | «Жилкомфортсервис» ИК ЖЧЖ; | 440 | 1683 | 1010 | |
| 18 | Торак йорнынţ подвалы | Алабуга шәһәре, Пролетарская урамы, 10 нчы йорт | «Жилкомфортсервис» ИК ЖЧЖ; | 430 | 2061 | 1237 | |
| 19 | Торак йорнынţ подвалы | Алабуга шәһәре, Пролетарская урамы, 16 нчы йорт | «Жилкомфортсервис» ИК ЖЧЖ; | 600 | 1913 | 1148 | |
| 20 | Торак йорнынţ подвалы | Алабуга шәһәре, Пролетарская урамы, 38 нче йорт | «Жилкомфортсервис» ИК ЖЧЖ; | 2180 | 2866 | 1720 | |
| 21 | Торак йорнынţ подвалы | Алабуга шәһәре, Пролетарская урамы, 44 нче йорт | «Жилкомфортсервис» ИК ЖЧЖ; | 530 | 1215 | 729 | |
| 22 | Торак йорнынţ подвалы | Алабуга шәһәре, Пролетарская урамы, 50 нче йорт | «Жилкомфортсервис» ИК ЖЧЖ; | 135 | 773 | 464 | |
| 23 | Торак йорнынţ подвалы | Алабуга шәһәре, Пролетарская урамы, 52 нче йорт | «Жилкомфортсервис» ИК ЖЧЖ; | 189 | 585 | 351 | |
| 24 | Торак йорнынţ подвалы | Алабуга шәһәре, Разведчиклар урамы, 46 нчы йорт | «Жилкомфортсервис» ИК ЖЧЖ; | 150 | 396 | 238 | |
| 25 | Торак йорнынţ подвалы | Алабуга шәһәре, Разведчиклар урамы, 48 нче йорт | «Жилкомфортсервис» ИК ЖЧЖ; | 150 | 578 | 347 | |
| 26 | Торак йорнынţ подвалы | Алабуга шәһәре, Разведчиклар урамы, 50 нче йорт | «Жилкомфортсервис» ИК ЖЧЖ; | 150 | 578 | 347 | |
| 27 | Торак йорнынţ подвалы | Алабуга шәһәре, Разведчиклар урамы, 54 нче йорт | «Жилкомфортсервис» ИК ЖЧЖ; | 405 | 1856 | 1114 | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 28 | Торак йорнының подвалы | Алабуга шәһәре, Строители урамы, 13 нче йорт | «Жилкомфортсервис» ИК ҖЧҖ; | 340 | 1465 | 879 | |
| 29 | Торак йорнының подвалы | Алабуга шәһәре, Строители урамы, 15 нче йорт | «Жилкомфортсервис» ИК ҖЧҖ; | 315 | 713 | 428 | |
| 30 | Торак йорнының подвалы | Алабуга шәһәре, Строители урамы, 17 А нче йорт | «Жилкомфортсервис» ИК ҖЧҖ; | 202 | 1160 | 696 | |
| 31 | Торак йорнының подвалы | Алабуга шәһәре, Чулман урамы, 1 нче йорт | «Жилкомфортсервис» ИК ҖЧҖ; | 670 | 1136 | 682 | |
| 32 | Торак йорнының подвалы | Алабуга шәһәре, Чулман урамы, 9 нчы йорт | «Жилкомфортсервис» ИК ҖЧҖ; | 1200 | 1515 | 909 | |
| 33 | Торак йорнының подвалы | Алабуга шәһәре, Автомобилистлар урамы, 2 нче йорт | «Домуправ-3» ИК ҖЧҖ; | 320 | 893 | 536 | |
| 34 | Торак йорнының подвалы | Алабуга шәһәре, Автомобилистлар урамы, 4 нче йорт | «Домуправ-3» ИК ҖЧҖ; | 460 | 1266 | 760 | |
| 35 | Торак йорнының подвалы | Алабуга шәһәре, Автомобилистлар урамы, 6 нчы йорт | «Домуправ-3» ИК ҖЧҖ; | 460 | 1416 | 850 | |
| 36 | Торак йорнының подвалы | Алабуга шәһәре, Автомобилистлар урамы, 7 нче йорт | «Домуправ-3» ИК ҖЧҖ; | 330 | 928 | 557 | |
| 37 | Торак йорнының подвалы | Алабуга шәһәре, Автомобилистлар урамы, 10 нчы йорт | «Домуправ-3» ИК ҖЧҖ; | 880 | 2431 | 1459 | |
| 38 | Торак йорнының подвалы | Алабуга шәһәре, Автомобилистлар урамы, 9 нчы йорт | «Домуправ-3» ИК ҖЧҖ; | 480 | 1340 | 804 | |
| 39 | Торак йорнының подвалы | Алабуга шәһәре, Автомобилистлар урамы, 12 нче йорт | «Домуправ-3» ИК ҖЧҖ; | 620 | 1728 | 1037 | |
| 40 | Торак йорнының подвалы | Алабуга шәһәре, Мәрҗани урамы, 12 нче йорт | «Домуправ-3» ИК ҖЧҖ; | 380 | 1048 | 629 | |
| 41 | Торак йорнының подвалы | Алабуга шәһәре, Мәрҗани урамы, 4 нче йорт | «Домуправ-3» ИК ҖЧҖ; | 1340 | 3730 | 2238 | |
| 42 | Торак йорнының подвалы | Алабуга шәһәре, Мәрҗани урамы, 12 нче йорт | «Домуправ-3» ИК ҖЧҖ; | 750 | 2086 | 1252 | |
| 43 | Торак йорнының подвалы | Алабуга шәһәре, Мәрҗани урамы, 16 нчы йорт | «Домуправ-3» ИК ҖЧҖ; | 880 | 2570 | 1542 | |
| 44 | Торак йорнының подвалы | Алабуга шәһәре, Мәрҗани урамы, 18 нче йорт | «Домуправ-3» ИК ҖЧҖ; | 540 | 1636 | 982 | |
| 45 | Торак йорнының подвалы | Алабуга шәһәре, Мәрҗани урамы, 28 нче йорт | «Домуправ-3» ИК ҖЧҖ; | 890 | 2803 | 1682 | |
| 46 | Торак йорнының подвалы | Алабуга шәһәре, Мәрҗани урамы, 32 нче йорт | «Домуправ-3» ИК ҖЧҖ; | 760 | 2145 | 1287 | |
| 47 | Торак йорнының подвалы | Алабуга шәһәре, Мир проспекты, 50 нче йорт | «Домуправ-3» ИК ҖЧҖ; | 620 | 1501 | 900,6 | |
| 48 | Торак йорнының подвалы | Алабуга шәһәре, Окружное шоссесы урамы, 25 нче йорт | «Домуправ-3» ИК ҖЧҖ; | 690 | 2118 | 1271 | |
| 49 | Торак йорнының подвалы | Алабуга шәһәре, Окружное шоссесы урамы, 29 нчы йорт | «Домуправ-3» ИК ҖЧҖ; | 720 | 2416 | 1450 | |
| 50 | Торак йорнының подвалы | Алабуга шәһәре, Окружное шоссесы урамы, 37 нче йорт | «Домуправ-3» ИК ҖЧҖ; | 1240 | 3485 | 2091 | |
| 51 | Торак йорнының подвалы | Алабуга шәһәре, Окружное шоссесы урамы, 45 нче йорт | «Домуправ-3» ИК ҖЧҖ; | 460 | 1496 | 898 | |
| 52 | Торак йорнының подвалы | Алабуга шәһәре, Окружное шоссесы урамы, 47 нче йорт | «Домуправ-3» ИК ҖЧҖ; | 540 | 1625 | 975 | |
| 53 | Торак йорнының подвалы | Алабуга шәһәре, Х.Нечаев урамы, 9 нчы йорт | «Домуправ-3» ИК ҖЧҖ; | 460 | 1486 | 892 | |
| 54 | Торак йорнының подвалы | Алабуга шәһәре Хирурга Нечаев урамы, 11 нче йорт | «Домуправ-3» ИК ҖЧҖ; | 890 | 2865 | 1719 | |
| 55 | Торак йорнының подвалы | Алабуга шәһәре Хирурга Нечаев урамы, 15 нче йорт | «Домуправ-3» ИК ҖЧҖ; | 460 | 1486 | 892 | |
| 56 | Торак йорнының подвалы | Алабуга шәһәре Хирурга Нечаев урамы, 16 а нчы йорт | «Домуправ-3» ИК ҖЧҖ; | 1750 | 4875 | 2925 | |
| 57 | Торак йорнының подвалы | Алабуга шәһәре Хирурга Нечаев урамы, 17 нче йорт | «Домуправ-3» ИК ҖЧҖ; | 890 | 3183 | 1910 | |
| 58 | Торак йорнының подвалы | Алабуга шәһәре, Парковая урамы, 2 нче йорт | «Дуслык» торак милекчеләре ширкәте | 70 | 500 | 300 | |
| 59 | Торак йорнының подвалы | Алабуга шәһәре, Парковая урамы, 4 нче йорт | «Дуслык» торак милекчеләре ширкәте | 70 | 500 | 300 | |
| 60 | Торак йорнының подвалы | Алабуга шәһәре, Парковая урамы, 6 нчы йорт | «Дуслык» торак милекчеләре ширкәте | 70 | 500 | 300 | |
| 61 | Торак йорнының подвалы | Алабуга шәһәре, Тысячелетие [illegible] | «Дуслык» торак милекчеләре | 100 | 666 | 400 | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 62 | Торак йорнынң подвалы | Алабуга шәһәре, Тысячелетие урамы, 2 нче йорт | «Дуслык» торак милекчеләре ширкәте | 100 | 666 | 400 | |
| 63 | Торак йорнынң подвалы | Алабуга шәһәре, Тысячелетие урамы, 4 нче йорт | «Дуслык» торак милекчеләре ширкәте | 100 | 666 | 400 | |
| 64 | Торак йорнынң подвалы | Алабуга шәһәре, Тысячелетие урамы, 6 нчы йорт | «Дуслык» торак милекчеләре ширкәте | 100 | 666 | 400 | |
| 65 | Торак йорнынң подвалы | Алабуга шәһәре, Тысячелетие урамы, 8 нче йорт | «Дуслык» торак милекчеләре ширкәте | 100 | 666 | 400 | |
| 66 | Торак йорнынң подвалы | Алабуга шәһәре, Тысячелетие урамы, 10 нчы йорт | «Дуслык» торак милекчеләре ширкәте | 100 | 666 | 400 | |
| 67 | Торак йорнынң подвалы | Алабуга шәһәре, Автомобилистлар урамы, 8 нче йорт | "Созвездие" ИК" ҖЧҖ | 468 | 2800 | 1680 | |
| 68 | Торак йорнынң подвалы | Алабуга шәһәре, Автомобилистлар урамы, 11 нче йорт | "Созвездие" ИК" ҖЧҖ | 164 | 1403 | 842 | |
| 69 | Торак йорнынң подвалы | Алабуга шәһәре, Болгар урамы, 6 нчы йорт | "Созвездие" ИК" ҖЧҖ | 154 | 2011 | 1207 | |
| 70 | Торак йорнынң подвалы | Алабуга шәһәре, Городищенская урамы, 4 нче йорт | "Созвездие" ИК" ҖЧҖ | 186 | 3995 | 2397 | |
| 71 | Торак йорнынң подвалы | Алабуга шәһәре, М. Горький урамы, 78а/2 нче йорт | "Созвездие" ИК" ҖЧҖ | 81 | 1125 | 675 | |
| 72 | Торак йорнынң подвалы | Алабуга шәһәре, Малая Покровскаяв урамы, 33 а/3 нче йорт | "Созвездие" ИК" ҖЧҖ | 123 | 1125 | 675 | |
| 73 | Торак йорнынң подвалы | Алабуга шәһәре, Малая Покровскаяв урамы, 33 а/4 нче йорт | "Созвездие" ИК" ҖЧҖ | 120 | 1125 | 675 | |
| 74 | Торак йорнынң подвалы | Алабуга шәһәре, Тугаров урамы, 20а/1 нче йорт | "Созвездие" ИК" ҖЧҖ | 134 | 1196 | 718 | |
| 75 | Торак йорнынң подвалы | Алабуга шәһәре, Интернациональная урамы, 8 нче йорт | "Кама" торак милекчеләре ширкәте | 112 | 826 | 496 | |
| 76 | Торак йорнынң подвалы | Алабуга шәһәре, Мәрҗани урамы, 6 нчы йорт | "Кама" торак милекчеләре ширкәте | 449 | 3168 | 1901 | |
| 77 | Торак йорнынң подвалы | Алабуга шәһәре, Пролетарская урамы, 54 нче йорт | "Кама" торак милекчеләре ширкәте | 100 | 895 | 537 | |
| 78 | Торак йорнынң подвалы | Алабуга шәһәре, Строители урамы, 23 нче йорт | "Кама" торак милекчеләре ширкәте | 87 | 721 | 433 | |
| 79 | Торак йорнынң подвалы | Алабуга шәһәре Хирурга Нечаев урамы, 5 нче йорт | "Кама" торак милекчеләре ширкәте | 473 | 3068 | 1841 | |
| 80 | Торак йорнынң подвалы | Алабуга шәһәре, Тугаров урамы, 8 нче йорт | "Прогресс" торак милекчеләре ширкәте | 2500 | 2658 | 1595 | |
| 81 | Торак йорнынң подвалы | Алабуга шәһәре, Тугаров урамы, 8 а нче йорт | "Прогресс" торак милекчеләре ширкәте | 2500 | 2583 | 1550 | |
| 82 | Торак йорнынң подвалы | Алабуга шәһәре, Бакый Урманче урамы, 17, 17/1 нче йорт | "Баки Урманче" торак милекчеләре ширкәте | 1820 | 2191 | 1315 | |
| 83 | Торак йорнынң подвалы | Алабуга шәһәре Мәрҗани урамы, 20 нче йорт | "Танайка" УО ҖЧҖ | 160 | 996 | 597,9 | |
| 84 | Торак йорнынң подвалы | Алабуга шәһәре Хирурга Нечаев урамы, 16 нчы йорт | "Нечаев-16" торак милекчеләре ширкәте | 460 | 460 | 276 | |
| 85 | Торак йорнынң подвалы | Алабуга шәһәре, Мир проспекты, 65 нче йорт | "Ромашка" торак милекчеләре ширкәте | 230 | 1043 | 626 | |
| 86 | Торак йорнынң подвалы | Алабуга шәһәре, Гассар урамы, 20 А нче йорт | ""Возрождение" "торак милекчеләре ширкәте | 100 | 2115 | 1269 | |
| 87 | Торак йорнынң подвалы | Алабуга шәһәре, Мир проспекты, 22 нче йорт | "Мирный" торак милекчеләре ширкәте | 1000 | 3873 | 2324 | |
| 88 | Торак йорнынң подвалы | Алабуга шәһәре, Мир проспекты, 69 нчы йорт | "Успех" торак милекчеләре ширкәте | 668 | 800 | 480 | |
| | БАРЛЫГЫ | 0 | 0 | 39959 | 112156 | 88301,5 | |

Лист согласования к документу № 1918 от 10.12.2025
Инициатор согласования: Каретина К.Д. Главный специалист
Согласование инициировано: 11.12.2025 13:35

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Томилин А.А. | | Подписано 11.12.2025 - 14:08 | - |